**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының аерым указларын үз көчен югалткан дип тану турында

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Торак базарын формалаштыру шартларында гражданнарның милеккә хокукларын яклау чаралары турында» 1994 елның 19 мартындагы ПУ-214 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указлары үз көчен югалткан дип турында» 1995 елның 21 июнендәге ПУ-405 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Тузган торак фондын бетерү һәм тузган торак кварталларын реконструкцияләү буенча өстәмә чаралар турында» 1997 елның 9 июнендәге ПУ-284 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Тузган торак фондында яшәүче гражданнарга торак йортлар бирүнең кайбер үзенчәлекләре турында» 1999 елның 2 сентябрендәге ПУ-705 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында тузган торак фондын бетерү һәм тузган торак кварталларын реконструкцияләү программасын гамәлгә ашыру буенча өстәмә чаралар турында» 2000 елның 23 июнендәге ПУ-458 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен гражданнар тарафыннан документлар җыйганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру чаралары турында» 2008 елның 20 февралендәге ПУ-77 номерлы Указы;

«Татарстан Республикасы Президентының «Күчемсез мөлкәткә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларны дәүләт теркәвенә алу өчен гражданнар тарафыннан документлар җыйганда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнары территориаль органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген оештыру чаралары турында» Указына үзгәрешләр

кертү хакында» Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 22 июнендәге ПУ-395 номерлы Указы.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2018 ел, 27 ноябрь
№ ПУ-808